ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); № 36 (I өлеш); № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «һәм срокларын» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләрен» сүзләрен «, салым түләүчеләр тарафыннан аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяның $2^1$ өлешендә «2020 һәм 2021» сүзләрен «2020 – 2023» саннарына алмаштырырга;

3) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4 статья. **Салым түләү тәртибе**

Салым түләүчеләр салым чоры тәмамланганнан соң салым, шулай ук хисап чоры нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда салым буенча аванс түләүләре түлиләр.».

**Статья 2**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 66-ТРЗ